**МИНИСТЕРСТВО ПРОСВЕЩЕНИЯ РОССИЙСКОЙ ФЕДЕРАЦИИ**

**Министерство образования и науки Республики Башкортостан**

**МКУ Отдел образования администрации МР Кигинский район РБ**

**МОБУ СОШ с. Еланлино МР Кигинский район РБ**

| РАССМОТРЕНО | СОГЛАСОВАНО | УТВЕРЖДЕНО |
|---|---|---|
| Руководитель ШМО учителей начальных классов | Зам. директора по УВР | Директор |
| ________ШаиховаЛ.Н. | ________Шарафутдинова Г. Л. | ________Шаихова Р. Р. |
| Приказ №5 от «31» 05 23 г. | от «31» 08 23 г. | Приказ №229 от «01» 09 23 г. |

# РАБОЧАЯ ПРОГРАММА

## учебного предмета «Родной язык»

для обучающихся 1 – 4 классов

с. Еланлино 2023

# Аңлатма язуы

## 1. Укыту предметының гомуми характеристикасы

**Татар теле дәресенең максаты:**

-укучыларда уңышлы аралашу сәләте булдыру-әйтмә һәм язма сөйләмне үстерү, кара-каршы сөйләшү осталыгы, монолог төзү һәм шулай ук гомуми культура күрсәткече булган грамоталы язу күнекмәләре булдыру, укучыларны тел фәненең төп мәгълуматлары белән таныштыру һәм шулар нигезендә аларның тамга символик һәм логик фикерләвен үстерү, татар теленең башка телләр белән берлектә дөньяның фәнни

картинасын тудыруда катнашуы,аның милләте саклап калуда, халыкның, шәхеснең үзенчәлеген югалтмауда ышанычлы нигез, җәмгыятнең яшәешенә зарури шарт булуы турында күзаллау барлыкка китерү.

**Бурычлар:**

- балаларның сөйләм осталыгын, фикерләү сәләтен һәм иҗади хыялын үстерү, ана телендә аралашу максатына, бурычларына,шартларына туры килгән тел чаралары сайлый белергә, уй-фикерләрен төгәл белдерергә һәм әңгәмәдәше әйткәнне тәңгәл аңларга күнектерү
- телнең лексикасы,фонетикасы һәм грамматикасы буенча программада күрсәтелгән башлангыч белемнәрне үзләштерүгә ирешү
- укучыларда дөрес уку һәм язу күнекмәләре булдыру, диологта катнашырга һәм аларны зур, катлаулы булмаган монолог тибында төзеп әйтергә, тасфирлама, хикәяләү, фикер йөртү төрендәге кечкенә текстлар төзергә өйрәтү, уңышлы аралашу сәләте тәрбияләү.

Башлангыч сыйныфларда ана телен өйрәнү –балаларга тел белеме буенча системалы мәгълүматләр бирү һәм сөйләм үсешен тәэмин итүдә беренчел этап.Бу чорда ана телен өйрәнү башка фәннәр белән тыгыз бәйләнештә алып барыла.Татар теле дәресләрендә телнең системасы тирәнтен өйрәнелә,сөйләм культурасы үзләштерелә. Кече яшьтәге балаларның аралашу гамәлендә актуаль булган ситуацияләрдә кирәкле осталык һәм күнекмәләр булдырыла, сөйләм жанрының төрләре (записка,хат,котлау, чакыру язу) үзләштерелә.Орфография һәм пунктуацион кагыйдәләре фонетика,морфология, морфемика һәм синтаксисны өйрәнү кысаларында үзләштерелә.Ана теленең орфография принциплары белән танышу да кертелә.

Эш программасының максаты һәм бурычлары – укучыларның телдән һәм язма сөйләмен үстерү, барлык сөйләм эшчәнлеге төрләре буенча да сөйләмнәрен камилләштерү; ана телен өйрәнү белән кызыксынуларын тәэмин итү; татар теленең бүлекләре буенча беренчел лингвистик мәгълүмат бирү; аралашу, лингвистик, этнокультура буенча компетенцияләрен

формалаштыру, универсаль уку гамәлләрен булдыру; ана теленә карата уңай мөнәсәбәт тәрбияләү; гражданлык һәм патриотик хисләр тәрбияләү.

**2. Татар телен туган тел буларак укыту предметын үзләштерүнең планлаштырылган нәтиҗәләре.**

Укыту предметын Стандарт таләпләрен һәм туган тел үзенчәлекләрен исәпкә алып үзләштерүдән көтелгән нәтиҗәләр алдагы этапта уңышлы белем алуны тәэмин итәргә тиеш:

- Россия Федерациясе халыкларының теле һәм мәдәниятенең күптөрле булуы турында башлангыч белем алу;
- телнең милли мәдәниятнең мөһим өлеше, төрле халыклар белән аралашу чарасы икәнлеген аңлау;
- телдән һәм язма сөйләмнең әдәби нормаларын өйрәнү;
- татар теленең өйрәнелгән программа материалы күләмендә аралашу өчен кирәк булган орфоэпик, лексик һәм грамматик нормаларын үзләштерү, татар сөйләм этикеты турында беренчел мәгълүмат туплау, тел материалын сайлап файдалану осталыгына ия булу;
- төрле тормыш ситуацияләренә бәйле рәвештә танып белү һәм аралашу эшчәнлегендә татар теленнән алган белемнәрне файдалану (сыйныфта, сыйныфтан тыш чараларда).

Телне үзләштерү нәтиҗәсендә, укучылар аның милли-мәдәни күренеш буларак аралашу чарасы икәнлеген аңлыйлар. 4 нче сыйныф ахырына ана теленең телдән һәм язма формаларына ия булуны кешенең гомуми культурасы үсеше күрсәткече дип кабул итә башлыйлар.

Татар телен өйрәнүнең шәхси, метапредмет һәм предметка караган нәтиҗәләре өч төркемгә аерыла.

***Шәхси*** **нәтиҗәләр:**

- ❖ Ватанга, телгә, мәдәнияткә карата мәхәббәт һәм хөрмәт тәрбияләү;
- ❖ кеше тормышында телнең һәм сөйләмнең әһәмиятлелегенә төшенү;
- ❖ башка кешеләрнең хис-тойгыларын аңлау, үзеңнең хисләреңне белдерергә өйрәнү;
- ❖ башкаларның телдән һәм язма сөйләмнәренә хас булган үзенчәлекләренә игътибар итү;
- ❖ сөйләмгә (тыңлап аңлау, диалог һәм монолог төзү, язу), гомумән, телне өйрәнүгә карата кызыксыну уяту;
- ❖ әйткән яки язган сөйләмгә җаваплылык хисенең булуы.

***Метапредмет*** нәтиҗәләре татар телен өйрәнү вакытында универсаль уку гамәлләрен булдыруны күздә тота (УУГ):

- ❖ регулятив УУГ:

✓ мөстәкыйль рәвештә (укытучы ярдәмендә) дәреснең темасын һәм максатын әйтү;

✓ укытучы тәкъдим иткән план нигезендә эшләү;

✓ укуга караган проблеманы чишү өчен, укытучы белән бергә план төзү;

✓ куелган максат буенча план нигезендә эшләү, кирәк булган очракта, үзеңнең эшчәнлегеңә төзәтмәләр кертү;

✓ дәрестә эшләгәндә, үзеңнең фикереңне әйтергә өйрәнү.

❖ танып белү УУГ:

✓ дәреслектәге текстлардан һәм рәсемнәрдән җаваплар табу;

✓ укытучының сыйныф белән бергә эшләвенә нәтиҗә ясау;

✓ мәгълүматны бер формадан икенче формага күчерү;

✓ текстларның эчтәлеген сөйләү;

✓ кирәкле вакытта сүзлекләрдән һәм белешмә әдәбияттан файдалану;

✓ укуның барлык төрләреннән файдалану;

✓ фикер алышуда катнашу.

❖ аралашу УУГ:

✓ монологик һәм диалогик сөйләмгә ия булу;

✓ сөйләм ситуациясеннән чыгып, үзеңнең фикереңне телдән һәм язма формада белдерү;

✓ башкаларны ишетә һәм тыңлый белү, чит кеше фикерен дөрес кабул итү һәм кирәк булган очракта, үзеңнекен үзгәртү;

✓ текстны сәнгатьле итеп уку һәм эчтәлеген сөйләү;

✓ үзеңнең фикереңне нигезләп әйтә белү;

✓ сораулар бирү;

✓ икешәрләп һәм төркем белән эшләү, төрле вазифалар башкару: башкаручы, җитәкче һ.б.

***Предметка*** **караган УУГ:**

✓ укытучы яки укучы укыган текстны аңлау;

✓ сүзләрдәге үзенчәлекле авазларны дөрес итеп әйтү;

✓ аваз-хәреф анализы ясау, авазларның һәм хәрефләрнең туры килү-килмәвен әйтү;

✓ текстны бәйләнешсез җөмләләрдән аеру;

✓ текстны кисәкләргә бүлү һәм аларга исем бирү;

✓ текстның тулы эчтәлеген сөйләү;

✓ текст исеменең мәгънәсен аңлау, бирелгән вариантлардан дөресен сайлап алу;

✓ аңлап, сүзләрне тутырып, сәнгатьле һәм дөрес итеп уку;

- ✓ сүзләрне, җөмләләрне, текстны укытучы укыганнан соң дөрес итеп язу һәм дөреслеген тикшерү;
- ✓ рәсем буенча телдән хикәя төзү;
- ✓ программада караган теоретик мәгълүматны белү.

Предмет нәтиҗәләре агымдагы һәм арадаш тикшерү вакытында, шулай ук йомгаклау максатыннан чыгып үткәрелә торган тикшерү эшләре ярдәмендә бәяләнә.

## 3. Татар телен туган тел буларак укыту предметының эчтәлеге.

Татар телен туган тел буларак укыту предметының уку материалы сөйләм эшчәнлеге төрләре (ишетеп (тыңлап) аңлау, сөйләү, уку, язу) һәм тел белеме бүлекләре буенча (фонетика һәм орфография, лексикология, сүз төзелеше һәм сүз ясалышы, морфология, синтаксис, орфография һәм пунктуация) төзелгән.

**Ишетеп аңлау.**

Ишеткән текстның эчтәлеген аңлау, аның буенча сорауларга җавап бирү, текстның төп мәгънәсен ачыклау максатыннан чыгып, әңгәмә оештыру.

**Сөйләү.**

Өйрәнгән сөйләм берәмлекләрен сөйләм ситуацияләрендә файдалану. Ана теленең орфоэпик һәм интонация нормаларын саклап, диалоглар һәм монологлар төзү. Уку процессында һәм сыйныфтан тыш чараларда төрле темалар буенча сөйләм этикеты үрнәкләрен куллану.

**Уку.**

Орфоэпия нормаларын саклап, логик басымнарны билгеләп укыган текстның эчтәлеген аңлау. Текстның темасын һәм төп фикерен аңлата белү.

**Язу.**

Авазларны, аваз тезмәләрен, иҗекләрне, сүзләрне һәм җөмләләрне язу күнекмәләрен булдыру. Әйтеп яздыру, өйрәнгән тема буенча текстны күчереп язу. Рәсем, видеоязма буенча, күргән яки ишеткән материалны өстәп, зур булмаган текст төзү.

**Фонетика.**

Авазлар һәм хәрефләр. Ишеткән сүздән сузык һәм тартык авазларны аеру. Аваз һәм хәрефләрнең санын һәм эзлеклеген билгеләү. Бер яки берничә хәрефе яки авазы белән аерылып торган сүзләрне чагыштыру.

Сузык һәм тартык, калын һәм нечкә, басымлы һәм басымсыз, яңгырау һәм саңгырау авазларны аеру.

Иҗек. Сүзне иҗекләргә бүлү. Басымлы иҗекне билгеләү.

**Графика**.

Хәреф һәм аваз турында төшенчә. Сузык һәм тартык аваз хәрефләре. Калын һәм нечкә сузыклар, аларны белдергән хәрефләр. Калын һәм нечкә әйтелешле сүзләрне чагыштыру, алардагы сузык авазларның әһәмияте. *Е - Ё, Ю, Я* хәрефләре. Калынлык *(ъ)* һәм нечкәлек *(ь)* билгеләре.

**Уку**.

Иҗекләп уку күнекмәләрен формалаштыру (сузык аваз хәрефләренә карап, сүзләрне калын һәм нечкә итеп әйтеп уку). Әдәби әйтелеш нормаларын саклап, тиешле тизлек белән иҗекләрне һәм бөтен сүзләрне салмак итеп уку. Сүзләрне, сүзтезмәләрне, җөмләләрне һәм кыска текстларны аңлап уку, гади җөмлә ахырындагы тыныш билгеләренә, җөмлә эчендәге тиңдәш кисәк, эндәш сүзләргә туры килгән интонация һәм паузаларга игътибар итеп уку. Зур булмаган текстны һәм шигырьләрне аңлап һәм сәнгатьле итеп уку күнекмәләрен шомарту.

Тулы сүзләрне укуга күчкәч, кайбер орфоэпик нормалар белән танышу.

**Язу**.

Язганда тиешле гигиена таләпләрен үтәү. Язганда, кул һәм бармак мускулларының җитез һәм ритмик хәрәкәт итүләренә ирешү. Баш һәм юл хәрефләрнең язылышы. Гигиена нормаларын саклап, аерым хәрефләр, аларның кушылмасы, иҗек, сүз һәм җөмләләрне язу. Әйтелеше белән язылышы арасында аерма булмаган сүз һәм җөмләләрне яздыру. Дөрес күчереп язу алымнарын һәм эзлеклелеген үзләштерү. Сүзләр арасында буш урын калдыру, күчерү билгесе кую кебек график чараларның әһәмиятен аңлау.

**Сүз һәм җөмлә**.

Сүз һәм аның лексик мәгънәсе. Сүзләрнең мәгънә ягыннан төрләрен күзәтү. Сүзне һәм җөмләне аеру. Җөмләдәге сүзләрне һәм аларның урнашу тәртибен үзгәртү.

**Орфография**.

Дөрес язу кагыйдәләре һәм аларның кулланылышы белән таныштыру:

- сүзләрнең аерым язылышы;
- о-ө хәрефләренең татар сүзләренең беренче иҗегендә генә язылуы;
- җөмлә башындагы сүзне баш хәреф белән язу, җөмлә ахырында нокта, сорау һәм өндәү билгеләрен кую;
- сүзләрне иҗекләргә бүлү һәм юлдан-юлга иҗекләп, дөрес итеп күчерү.

**Сөйләм үстерү**.

Үзең укыган яки тыңлаган текстның эчтәлеген аңлау. Сюжетлы рәсемнәр, уйнаган уеннар һәм күзәтүләргә таянып, зур булмаган хикәяләр төзү.

## Тел системасын гамәли яктан үзләштерү

**Фонетика һәм орфоэпия**.

Сузык һәм тартык авазларны аеру. Сүзләрдә басымлы һәм басымсыз сузык авазларны табу. Нечкә һәм калын тартык авазларны аеру, парлы һәм парсыз тартык авазларны билгеләү. Яңгырау һәм саңгырау тартыкларны аеру, аларның парларын билгеләү. Авазларга түбәндәгечә характеристика бирү: сузык-тартык; басымлы-басымсыз; калын-нечкә, яңгырау-саңгырау тартык. Сүзне иҗекләргә бүлү. Аваз һәм аваз кушылмаларының, сүз басымының хәзерге әдәби тел нормаларына туры килгән әйтелеше. Сүзгә фонетик анализ ясау элементлары.

**Графика.**

Аваз һәм хәрефне аеру. Язуда тартык авазларның калынлыгын һәм нечкәлеген билгеләү. Язуда аеру билгеләрен (ъ һәм ь) куллану. *Е - Ё, Ю, Я* хәрефләре булган сүзләрдә аваз һәм хәреф бәйләнешен билгеләү. Сүзләр арасында буш урын калдыру, күчерү билгесе кую, кызыл юл (абзац) кебек график чараларны куллану. Алфавиттагы хәрефләрнең дөрес исемен, аларның эзлеклелеген белү. Сүзлекләр, белешмәләр, каталоглар белән эшләгәндә, алфавиттан файдалана белү.

**Лексика**.

Сүзне яңгыраш һәм мәгънә берлеге буларак аңлау. Мәгънәсе төгәллек таләп итә торган сүзләрне барлау. Сүз мәгънәсен тексттан яки аңлатмалы сүзлек ярдәмендә билгеләү. Сүзнең бер һәм күп, туры һәм күчерелмә мәгънәле булуын, сөйләмдә синоним һәм антонимнарның кулланылышын күзәтү.

**Сүз төзелеше һәм сүз ясалышы.**

Тамырдаш сүзләр турында төшенчә бирү. Аларны синоним һәм омоним булган сүзләрдән аеру. Сүз тамырын һәм кушымчаны билгеләү.

Сүз ясагыч кушымчалар турында төшенчә бирү. Тамырдаш сүзләрнең төрле сүз ясагыч кушымчалар ярдәмендә ясалуы. Сүз составын тикшерү күнегүләре үтәү.

**Морфология**.

Сүз төркемнәре турында төшенчә бирү. Исем, аның мәгънәсе һәм сөйләмдә кулланылышы. Исемнәрнең сораулары. Кем? нәрсә? соравына җавап биргән исемнәрне аеру. Ялгызлык һәм уртаклык исемнәрне таба белү. Исемнәрнең берлек һәм күплек сан формалары. Килеш сораулары.

Исемнәрнең килеш белән төрләнеше. Исемнәрнең төрле килеш формаларын билгеләү. Исемнең тартым белән төрләнеше. Исемгә морфологик анализ ясау күнегүләре.

Сыйфат, аның мәгънәсе һәм сөйләмдә кулланылышы. Сыйфатның сораулары. Сыйфатның төрле (төс, форма, күләм, характер һ.б. буенча) билгеләрне белдерүе. Сыйфатның җөмләдә исемгә бәйләнеп килүе. Сыйфат дәрәҗәләре. Сыйфатка морфологик анализ ясау.

Алмашлык. Алмашлык турында гомуми төшенчә. Зат алмышлыклары, аларның мәгънәсе һәм сөйләмдә кулланылышы. I, II, III зат алмашлыкларының берлек һәм күплек сан формалары, аларның килеш белән төрләнеше.

Фигыль, аның мәгънәсе һәм сөйләмдә кулланылышы. Нишли? нишләде? нишләр? нишләячәк? сорауларына җавап биргән фигыльләрне аеру. Фигыльнең зат-сан белән төрләнүе. Аның төрле заман формалары (хәзерге, үткән һәм киләчәк заманнар). Фигыльнең барлыкта һәм юклыкта килүе. Фигыльгә морфологик анализ ясау.

Рәвеш, аның мәгънәсе, сораулары һәм сөйләмдә кулланышы.

Бәйлекләр, аларның сөйләмдәге әһәмияте.

Кисәкчәләр *(да, дә, та, тә, гына, генә, кына, кенә, ук, үк, ич, бит).* Аларның дөрес язылышы.

**Синтаксис**.

Сүз, сүзтезмә һәм җөмләләрне аеру, аларның аермалы якларын аңлау. Әйтү максаты ягыннан хикәя, сорау, өндәү җөмләләр һәм аларны дөрес интонация белән уку, алардан соң кирәкле тыныш билгеләрен кую.

Җөмләнең баш кисәкләре. Баш һәм иярчен кисәкләр турында төшенчә. Сүзтезмәдәге сүзләр һәм җөмлә кисәкләре арасында мәгънә бәйләнешен сораулар ярдәмендә ачыклау.

Теркәгечле *(һәм, ә, ләкин)* һәм теркәгечсез тиңдәш кисәкле җөмләләрне табу һәм мөстәкыйль рәвештә төзү. Тиңдәш кисәкле җөмләләрдә санау интонациясе турында төшенчә.

Гади һәм кушма җөмләләрне аеру.

**Орфография һәм пунктуация**.

Орфографик зирәклек тәрбияләү, орфограмма урынына карап, сүзне сайлап язу.

Дөрес язу кагыйдәләрен куллану:

- сузык аваз хәрефләрен дөрес язу кагыйдәләре *(о, ө, э);*
- тартык аваз хәрефләрен дөрес язу;
- сүзне юлдан юлга күчерү;
- җөмлә башындагы беренче сүзне һәм кеше исемнәрен баш хәреф

белән язу;

- аеру билгеләре *(ъ, ь);*
- калын *(гъ, къ)* авазларының катылыгын белдерү;
- һәмзә [ ’ ] авазын белдерү;
- җөмлә ахырында нокта, сорау һәм өндәү билгеләре кую;
- тиңдәш кисәкле җөмләләрдә тыныш билгеләрен (өтер) кую.

**Сөйләм үстерү**.

Аралашу ситуациясен аңлау: аралашуның кем белән, кайда, нинди максат белән башкарылуы. Үз фикереңне әйтү һәм аны дәлилләү. Әңгәмә үткәрүнең төп күнекмәләрен үзләштерү (сүз башлау, әңгәмәгә кушылу, аны дәвам итү, игътибарны үзеңә җәлеп итү һ.б.). Уку һәм көндәлек аралашу шартларында сөйләм әдәбе нормаларын үзләштерү (сәламләү, хушлашу, гафу үтенү, рәхмәт әйтү, сорау яки үтенеч белән мөрәҗәгать итү). Татар телен йомшаграк белүче кешеләр белән аралашканда, сөйләм әдәбе үзенчәлекләрен истә тоту.

Аерым темага караган сурәтләү яки хикәяләү формасындагы сөйләм текстларын кулланып, телдән монологик сөйләм оештыру.

**Текст.**

Текст турында төшенчә, аның билгеләре. Тексттагы җөмләләрнең мәгънә бердәмлеге. Текстка исем бирү. Тексттагы җөмләләрнең, текст кисәкләренең (өлешләренең) эзлеклелеге (абзац).

Текст буенча комплекслы эш: аңа исем бирү, җөмлә һәм текст кисәкләренең эзлеклелеген аңлау.

Текстның планы. Бирелгән текст буенча план төзү яки бирелгән план буенча үз текстыңны төзү.

Текст типлары: сурәтләү һәм хикәяләү формасындагы текстлар, аларның үзенчәлекләре.

Котлау һәм хат язу. Язма сөйләмнең төгәллеген, дөреслеген һәм сәнгатьлелеген саклап, аерым текстлар төзү, бирелгән текстларны тикшерү, төзәтү, текстта синонимнар һәм антонимнарны куллану.

Изложение һәм сочинениенең төп төрләре белән танышу (хәзергә билгеләмәләрен ятламыйча гына): бирелгән текстны тулысынча яки аерым файдаланып, төрле урыннарын (сүзләрен) сайлап язган изложение, сочинение элементлары булган изложение, хикәяләү-сурәтләү формасындагы сочинение һ.б.

## I СЫЙНЫФ

## Телдән әзерлек чоры

Язуга куелган гигиена таләпләрен үзләштерү. Язганда бармакларның һәм кулларның хәрәкәтләнү үзенчәлекләрен үстерү. Дәфтәр битендә һәм сыйныф тактасында дөрес юнәлештә яза алу осталыкларын үстерү.

Сүзне өйрәнү объекты һәм анализлау материалы буларак кабул итү. Сүзнең мәгънәсенә төшенү.

Сүз һәм җөмләләрне аеру. Җөмләдән сүзләрне аеру, аларның тәртибен үзгәртү.

## Әлифба чоры

Хәрефләрдән иҗекләр төзү, аннан соң иҗекләрдән сүзләр, сүзләрдән сүзтезмәләр төзеп уку. Укучыларда сүзтезмәләрдән җөмләләр төзү күнекмәләре тәрбияләү. Сүзләрне иҗекләргә бүлү.

Эчтәлеген аңлап, кирәкле урыннарда паузалар белән сүз басымын дөрес куеп уку.

Әлифба чорында татар һәм рус телләрендә бердәй әйтелешле авазлар белән ([б], [п], [д], [т], [ж], [ш], [з], [с], [и], [й], [л], [м], [н], [р], [у], [ф], [ц], [щ]) танышу, алар кергән сүзләрне дөрес уку.

[а], [о], [э], [w], [гъ], [къ], [х], [ч], [ы] авазларының әйтелеш үзенчәлекләре һәм бу авазларны язуда дөрес күрсәтү.

Татар телендәге [ә], [ө], [ү], [җ], [ң], [һ] авазлары кергән сүзләрне, сүзтезмәләрне һәм җөмләләрне дөрес уку.

## Татар теле

**Сөйләм.**

Телдән һәм язма сөйләм. Аралашу әдәбе.

**Сүз һәм иҗек.**

Сүзләрне иҗекләргә бүлү. Иҗекләрне һәм сүзләрне дөрес әйтү һәм язу.

**Авазлар һәм хәрефләр.**

Алфавит. Баш хәрефтән языла торган сүзләр.

Сузык авазлар, аларның төрләре. Сүзләрне иҗекләргә бүлү, аларны юлдан-юлга күчерү. Басым.

Тартык авазлар, аларның төрләре.

Сузык һәм тартык аваз хәрефләрен дөрес уку һәм язу.

Предметны, аның эшен, хәрәкәтен һәм билгесен белдергән сүзләр. Аларның мәгънәләрен аңлату, сорауларын әйтү. Фигыльләрнең барлык-юклык формалары турында төшенчә бирү.

**Сүздән җөмләгә.** Җөмләләр ахырында куела торган тыныш билгеләре турында гомуми мәгълүмат. Сөйләмне барлыкка китерүдә җөмләнең әһәмияте. Анда сүзнең кем яки нәрсә турында баруын һәм алар турында нинди

яңалык хәбәр ителүен белдерә торган кисәкләрне билгеләү. Аерым сүзләрдән җөмләләр төзү, сүзләр арасындагы бәйләнешне аңлату.

Әзер тексттан сүз, сүзтезмә һәм җөмләләрне дөрес итеп күчереп язу. Аннан соң аларны укытучы әйтүе буенча язу, ул тәкъдим иткән сүзләрдән сүзтезмә һәм җөмләләр төзеп язу.

Аерым темалар буенча өйрәнгән сүзләрне, сүзтезмә һәм җөмләләрне диктант итеп язу. Матур язу күнегүләрен үтәү. Сөйләм күнекмәләрен булдыру өстендә даими эшләү.

**Бәйләнешле сөйләм үстерү.**

**I сыйныф укучыларының белем, осталык һәм күнекмәләренә таләпләр**

*“Фонетика һәм графика”* бүлекләре буенча

Авазлар белән хәрефләрне аерырга өйрәнү, сузык авазларның төрләрен үзләштерү, яңгырау һәм саңгырау тартык авазларны аеру. Татар алфавитындагы хәрефләрнең урнашу тәртибен белү, бирелгән сүзләрне алфавит тәртибендә язу, кирәкле мәгълүматны эзләп тапканда, алфавиттан файдалана белү.

Хәрефләрдән иҗекләр, иҗекләрдән сүзләр, сүзләрдән сүзтезмә һәм җөмләләр төзү, аларны дөрес итеп язу. Сүзләрне иҗекләргә бүлү, юлдан-юлга күчерү. Сүз басымын дөрес куеп уку.

*“Орфоэпия”* бүлеге буенча

Татар теленең үзенчәлекле сузык һәм тартык авазларын дөрес әйтү, бу авазларны белдергән хәрефләр булган сүзләрне дөрес язу. Татар теленең үзенчәлекле авазлары кергән сүзләрдәге аваз һәм хәрефләрне аеру.

*“Лексика”* бүлеге буенча

Уку елы ахырында I сыйныф укучылары «Телдән әзерлек чоры» өчен тәкъдим ителгән темалар буенча бирелгән сүзләрне аңлап, кара-каршы һәм монологик сөйләмдә кулланырга өйрәнә. Укытучы, сыйныфтагы укучыларның белем дәрәҗәләрен исәпкә алып, үрнәктә бирелгән сүзләрне үзгәртә ала.

*“Морфология”* бүлеге буенча

Җөмләләрдән исемнәрне, фигыльләрне, сыйфатларны табу. Баш хәреф белән языла торган исемнәр.

*“Синтаксис”* бүлеге буенча

Сүзтезмә һәм җөмлә белән танышу. Сүзтезмәдәге һәм җөмләдәге сүзләр бәйләнешен аңлау. Җөмлә ахырында куелган тыныш билгеләренең интонациягә бәйле булуын күрү.

## II сыйныф

## Авазлар һәм хәрефләр

Сузык авазлар һәм хәрефләр. Калын һәм нечкә сузыклар, аларны дөрес әйтү. Сингармонизм законы. Сузык авазларны белдерә торган хәрефләрнең дөрес язылышы.

Татар һәм рус телләрендә [а], [э], [о], [ө], [ы] авазларның әйтелеш үзенчәлекләре, бу сузыкларны белдерә торган хәрефләр һәм аларның дөрес язылышы. *Я, ю, е* хәрефләре, алар кергән сүзләрне дөрес уку һәм язу.

Тартык авазлар. Яңгырау һәм саңгырау тартыклар. Алар кергән сүзләрне дөрес әйтү һәм язу. [w], [гъ], [къ], [х], [ч] тартыкларын дөрес әйтү, аларны белдерә торган хәрефләрнең дөрес язылышы. Татар теленең үзенчәлекле тартыклары [җ], [ң], [һ]. Бу хәрефләр кергән сүзләрне дөрес язу күнекмәләре булдыру.

*Ц, щ* хәрефләре булган сүзләрне дөрес уку һәм язу.

*ъ* һәм *ь* хәрефләре кергән сүзләрне дөрес уку һәм язу.

Сүзлек һәм аңлатмалы диктантлар язу.

## Сүз

Сүзләрне иҗекләргә бүлү.

Иҗекләрнең калынлыгы-нечкәлеге сузык авазларга бәйле булуы. Сүз басымы турында мәгълүмат бирү.

Сүз тамыры. Аны дөрес табарга өйрәнү.

## Морфология

**Исем.** Аның мәгънәсе, сораулары турында белгәннәрне ныгыту. Ялгызлык исемнәр, аларның дөрес язылышы. Исемнәрнең берлек һәм күплек сан формалары. Күплек сан кушымчаларының дөрес язылышы, аларны рус теле белән чагыштыру.

**Фигыль.** Аның мәгънәсе, сораулары. Фигыльләрнең заман формалары турында төшенчә бирү. Аларны рус теле белән чагыштырып күрсәтү.

**Сыйфат. А**ның мәгънәсе, сораулары белән таныштыру. Предметның төрле билгеләрен белдерә торган сүзләр буларак, аларны сөйләмдә дөрес куллану.

Бирелгән җөмләләрдән, әзер тексттан өйрәнгән сүз төркемнәрен табу, андый сүзләрне русчадан татарчага тәрҗемә итү, сөйләмдә дөрес куллану.

**Синтаксис**

Сүзләрдән сүзтезмә һәм җөмләләр төзү. Җөмләнең баш кисәкләре турында мәгълүмат бирү, аларның урнашу тәртибен күзәтү, аны рус теле белән чагыштыру. Бирелгән сүзләр белән сүзтезмәләр һәм җөмләләр төзү күнекмәләре тәрбияләү. Тәрҗемә күнекмәләре булдыру.

**Ел буена үткәннәрне гомумиләштереп кабатлау.**

**Бәйләнешле сөйләм үстерү.**

## II сыйныф укучыларының белем, осталык һәм күнекмәләренә таләпләр

*“Фонетика, графика һәм орфоэпия”* бүлекләре буенча

Калын һәм нечкә сузыкларны аерып, татар телендәге сүзләрнең сингармонизм законына буйсынуын (буйсынмавын) аңлау. Сүз басымын дөрес кую.

Яңгырау һәм саңгырау тартыкларны аеру; *ъ* һәм *ь* хәрефләре булган сүзләрне дөрес уку һәм язу (кулъяулык, көньяк); *я, ю, е* хәрефләрен дөрес язу.

Сүзләрдәге авазлар һәм хәрефләрне аеру, аларның санын һәм төрләрен күрсәтү. Сөйләмдә татар әдәби теленә хас булган орфоэпик нормаларны үтәү.

*“Сүз төзелеше”* бүлеге буенча

Сүзләрнең тамырын һәм кушымчасын билгеләү, тамырдаш сүзләрне дөрес табу.

*“Лексика”* бүлеге буенча

Мәгънәсен ачыкларга кирәк булган сүзләрне табу, аны сүзлектән табып әйтү (күрсәтү).

*“Морфология”* бүлеге буенча

Сүз төркемнәреннән исем, фигыль һәм сыйфатларның мәгънәләрен аңлап, җөмлә эченнән табу. Исемнәрнең берлек һәм күплек сан формаларын аеру, фигыльләрнең юклык һәм заман кушымчаларын билгеләү, сыйфатланмышны табу, аның сыйфат белән бәйләнешен күзәтү. Өйрәнелә торган сүз төркемнәре кергән мәкаль-әйтем, табышмакларны ятлау һәм аларны язу.

*“Синтаксис”* бүлеге буенча

Җөмләнең баш кисәкләрен билгеләү, аларның урнашу тәртибен күзәтү. Җөмлә кисәкләре һәм сүз төркемнәре дигән төшенчәләрне аеру. Әйтү максаты буенча төрле булган җөмләләр ахырында тыныш билгеләрен кую.

## III  с ы й н ы ф

### Сүз

Әйтелеш һәм мәгънә бердәмлеге буларак сүз, аның туры һәм күчерелмә мәгънәләре. Синонимнар, омонимнар һәм антонимнар. Аларны тексттан табу, сөйләмдә дөрес һәм урынлы куллана белү.

Сүзлекләр турында мәгълүмат бирү һәм алар белән эшләргә өйрәтү. Сүзлек диктантлары язу.

### Сүз төзелеше һәм ясалышы

Тамыр һәм кушымча. Ясалма сүзләр. Тамырдаш сүзләр. Татар һәм рус телләрендә сүзләргә кушымчаларның ялгану тәртибе һәм үзенчәлекләре. Кушма һәм парлы сүзләр.

### Морфология

**Исем** турында өйрәнгәннәрне искә төшерү. Уртаклык һәм ялгызлык исемнәр. Исемнәрнең килеш белән төрләнүе турында мәгълүмат бирү. Борын авазларына беткән исемнәрнең килеш белән төрләнеше.

**Сыйфат** турында белгәннәрне искә төшерү һәм ныгыту. Синоним һәм антоним сыйфатлар. Аларны сөйләмдә дөрес куллану. Сыйфатларның җөмләдәге роле. Татар телендә сыйфат белән сыйфатланмышның бәйләнеше.

**Сан.** Аның мәгънәсе, сораулары, сөйләмдә дөрес куллану. Сан белән саналмышның бәйләнеше.

**Алмашлык.** Зат алмашлыклары. Аларның мәгънәсе, килеш белән төрләнеше. Сорау алмашлыклары турында мәгълүмат бирү.

**Фигыль** турында өйрәнгәннәрне искә төшерү, аның заманнары. Хәзерге заман хикәя фигыльләрнең зат-сан белән төрләнеше, аларның сөйләмдә дөрес кулланылышы. Рус телендәге фигыльләрнең заманнары һәм зат-сан белән төрләнешендәге үзенчәлекләр.

### Синтаксис

Өйрәнелгән сүз төркемнәрен  кулланып, сүзтезмә һәм җөмләләр төзү, аларны сөйләмдә дөрес куллану.

Әйтү максаты буенча җөмлә төрләре: хикәя, сорау, боеру һәм тойгылы җөмләләр. Җөмләнең баш кисәкләрен билгели белү.

Аергыч турында мәгълүмат бирү, аларны сөйләмдә дөрес куллану. Русча җөмләләрне татарчага тәрҗемә итү.

Татар телендә җөмләдәге сүз тәртибе  (ия белән хәбәрнең, аергыч белән аерылмышның урыннары).

**Ел буена үткәннәрне гомумиләштереп кабатлау.**

**Бәйләнешле сөйләм үстерү.**

**III сыйныф укучыларының белем, осталык һәм күнекмәләренә таләпләр**

*“Лексика”* бүлеге буенча

Сүзнең туры һәм күчерелмә мәгънәсен, күп мәгънәле булуын аеру. Синоним, омоним, антоним сүзләрне дөрес билгеләп, аларны сүзтезмә һәм җөмлә төзегәндә куллану.

Төрле типтагы сүзлекләр белән эшләү.

*“Сүз төзелеше һәм сүз ясалышы”* бүлекләре буенча

Сүз төзелешен тикшерү күнегүләре үтәү. Укытучы биргән сүзләрнең тамырын һәм кушымчасын табу. Кушма һәм парлы сүзләрнең ясалышын аңлату, язылышын күзәтү. Алар белән җөмләләр төзү, сүзлек һәм аңлатмалы диктантлар язу.

*“Морфология”* бүлеге буенча

Уртаклык һәм ялгызлык исемнәрне аеру, борын авазларына беткән исемнәрне килеш белән төрләндерү; сыйфатларның сыйфатланмышка, саннарның саналмышка иярү үзенчәлеген аңлау. Саналмышның татар телендә берлек санда кулланылуы. Зат һәм сорау алмашлыкларын башка сүз төркемнәреннән аеру, аларны диалогик һәм монологик сөйләмдә куллану. Фигыльләрнең заманнарын билгеләү, хәзерге заман хикәя фигыльләрнең зат-сан белән төрләнешен язма һәм телдән сөйләмдә дөрес куллану.

*“Синтаксис”* бүлеге буенча

III сыйныфта өйрәнелгән сүз төркемнәрен кулланып, сүзтезмә һәм җөмләләр төзү. Әйтү максаты буенча төрле җөмләләрне аеру, аларның ахырында тыныш билгеләрен кую. Раслау һәм инкяр җөмләләрне билгеләү.

Җөмләнең баш кисәкләрен табу, ия белән хәбәрнең урнашу тәртибен күзәтү. Иярчен кисәклärдән аергычны билгеләү, аның аерылмышка иярү үзенчәлеген аңлау.

## IV сыйныф

## Морфология

**Исем.** Яңгырау, саңгырау һәм борын авазларына беткән исемнәрнең килеш белән төрләнеше. Аларның дөрес әйтелеше, язылышы һәм сөйләмдә дөрес кулланылышы.

**Сыйфатның** дәрәҗә формалары, аларның дөрес язылышы. Рус телендәге сыйфат дәрәҗәләреннән аермсы.

**Сан.** Микъдар һәм тәртип саннары. Аларның сөйләмдәге әһәмияте, дөрес куллану күнекмәләре. Татар телендә саналмышның кулланылу үзенчәлекләре.

**Алмашлыклар.** Күрсәтү алмашлыклары, аларның сөйләмдәге әһәмияте. Рус телендә бу алмашлыкларның мәгънәләрен белдерү юллары.

**Фигыль.** Үткән һәм киләчәк заман хикәя фигыльләр. Аларның зат-сан белән төрләнеше.

Хикәя фигыльләрнең барлык заман формаларын зат-сан белән төрләндерү, аларны сөйләмдә дөрес куллану.

**Синтаксис**

Татар һәм рус телләрендә сүзтезмә һәм җөмлә, аларда сүзләрнең урнашу тәртибе.

Җөмләнең баш кисәкләре. Иянең исем һәм зат алмашлыклары белән белдерелүе.

Хәбәрнең хикәя фигыль һәм сыйфатлар белән белдерелүе.

Җөмләнең иярчен кисәкләреннән аергыч, аның сыйфат һәм тәртип саннары белән белдерелүе.

Тәмамлык турында мәгълүмат.

Җыйнак һәм җәенке җөмләләр.

**Ел буена үткәннәрне гомумиләштереп кабатлау.**

**Бәйләнешле сөйләм үстерү.**

**IV сыйныф укучыларының белем, осталык һәм күнекмәләренә таләпләр**

*“Фонетика һәм графика”* бүлеге буенча

4 нче сыйныф ахырына аваз һәм хәреф төшенчәләре арасындагы аерманы аңлау, өйрәнгән күләмдә авазларга характеристика бирү, алфавиттагы хәрефләрнең урынын белү, аны гамәли эштә куллану.

*“Орфоэпия”* бүлеге буенча

Дәресләрдә һәм көндәлек тормышта татар әдәби теленә хас булган әйтелеш нормасын саклау, әйтү максаты төрле булган җөмләләрне әйтү кагыйдәләрен үтәү.

*“Лексика”* бүлеге буенча

Синоним, омоним һәм антонимнарны сөйләмдә урынлы куллану, төрле сүзлекләрне гамәли эштә файдалану. IV сыйныф ахырында укучыларда төрле типтагы сүзлекләр белән эшләү күнекмәләрен үстерү.

*“Сүз төзелеше һәм сүз ясалышы”* бүлекләре буенча

Сүзләрнең тамырын һәм кушымчаларын табу. Төрле сүз төркемнәрен (исем, сыйфат, фигыльләрне) ясаучы кушымчаларны күрсәтү.

Укытучы тәкъдим иткән сүзләрнең тамырын һәм ясагыч кушымчаларын билгеләү.

*“Морфология”* бүлеге буенча

Яңгырау, саңгырау һәм борын авазларына беткән исемнәрне килеш белән төрләндерү. Исемнәргә морфологик анализ ясау күнекмәләре булдыру (уртаклык яки ялгызлык булуы, берлектә яки күплектә килүе, килеше, нинди җөмлә кисәге булып килүен күрсәтү).

Сыйфатларның төрле дәрәҗә формалары (гади, чагыштыру, артыклык һәм кимлек). Дәреслектә һәм укытучы тарафыннан бирелгән сыйфатларның төрле дәрәҗә формаларын ясап, алар белән җөмләләр төзү.

Микъдар һәм тәртип саннарын билгеләү, аларны сөйләмдә дөрес куллану.

Күрсәтү алмашлыкларын телдән һәм язма сөйләмдә дөрес куллану.

Хикәя фигыльләрнең барлык заманнарын зат-сан белән төрләндереп, аларны телдән сөйләмдә, изложение һәм сочинение язганда дөрес куллану.

*“Синтаксис”* бүлеге буенча

Җөмләнең баш кисәкләрен табып, аларның нинди сүз төркеме белән белдерелүенә (иянең исем яки зат алмашлыгы, хәбәрнең хикәя фигыль яки сыйфат белән) мисаллар әйтү, укытучы күрсәткән (мөстәкыйль рәвештә укучы үзе тапкан) әдәби тексттан баш кисәкләрне күрсәтү.

Җөмләнең иярчен кисәкләреннән аергычның сыйфат һәм сан белән белдерелүен күрсәтү. Тәмамлыкның төрле килештәге исемнәр белән белдерелүен билгеләү.

Җөмләгә синтаксик анализ ясау күнекмәләре булдыру (ия, хәбәр, аергыч һәм тәмамлыкны күрсәтә белү).

Җыйнак һәм җәенке җөмләләрне телдән һәм язма сөйләмдә дөрес куллану.

## 4. Татар телен туган тел буларак укыту предметының уку эшчәнлеге төрләре күрсәтелгән тематик планы.

| Программаның төп темалары | Сәг. саны | Уку эшчәнлегенең төп төрләре |
|---|---|---|
| **1 сыйныф** | | |
| Телдән әзерлек чоры. | 4 | Язуга куелган гигиена таләпләрен үзләштерү. Язганда бармакларның һәм кулларның хәрәкәтләнү үзенчәлекләрен үстерү. Дәфтәр битендә һәм сыйныф тактасында дөрес юнәлештә язу осталыкларын үстерү. Сүзне өйрәнү объекты һәм анализлау материалы буларак кабул итү. Сүзнең мәгънәсенә төшенү. |

| | | |
|---|---|---|
| | | Сүз һәм җөмләләрне аеру. Җөмләдән сүзләрне аеру, аларның тәртибен үзгәртү. |
| Әлифба чоры. | 27 | Хәрефләрдән иҗекләр төзү, аннан соң иҗекләрдән сүзләр, сүзләрдән сүзтезмәләр төзеп уку. Укучыларда сүзтезмәләрдән җөмләләр төзү күнекмәләре тәрбияләү. Сүзләрне иҗекләргә бүлү.<br>Эчтәлеген аңлап, кирәкле урыннарда паузалар белән сүз басымын дөрес куеп уку.<br>Әлифба чорында татар һәм рус телләрендә бердәй әйтелешле авазлар белән ([б], [п], [д], [т], [ж],[ш], [з], [с], [и], [й], [л], [м], [н], [р], [у], [ф], [ц], [щ]) танышу, алар кергән сүзләрне дөрес уку.<br>[а], [о], [э], [w], [гъ], [къ], [х], [ч], [ы] авазларының әйтелеш үзенчәлекләре һәм бу авазларны язуда дөрес күрсәтү.<br>Татар телендәге [ә], [ө], [ү], [ж], [ң], [һ] авазлары кергән сүзләрне, сүзтезмәләрне һәм җөмләләрне дөрес уку. Телдән һәм язма сөйләм. Аралашу әдәбе. Сүзләрне иҗекләргә бүлү. Иҗекләрне һәм сүзләрне дөрес әйтү һәм язу. Алфавит. Баш хәрефтән языла торган сүзләр.<br>Сузык авазлар, аларның төрләре. Сүзләрне иҗекләргә бүлү, аларны юлдан-юлга күчерү. Басым.<br>Тартык авазлар, аларның төрләре.<br>Сузык һәм тартык аваз хәрефләрен дөрес уку һәм язу.<br>Предметны, аның эшен, хәрәкәтен һәм билгесен белдергән сүзләр. Аларның мәгънәләрен аңлату, сорауларын әйтү. Фигыльләрнең барлык-юклык формалары турында төшенчә бирү.<br>Җөмләләр ахырында куела торган тыныш билгеләре турында гомуми мәгълүмат. Сөйләмне барлыкка китерүдә җөмләнең әһәмияте. Анда сүзнең кем яки нәрсә турында баруын һәм алар турында нинди яңалык хәбәр ителүен белдерә торган кисәкләрне билгеләү. Аерым сүзләрдән җөмләләр төзү, сүзләр арасындагы бәйләнешне аңлату. |
| Әлифбадан соңгы чор | 2 | Әзер тексттан сүз, сүзтезмә һәм җөмләләрне дөрес итеп күчереп язу. Аннан соң аларны укытучы әйтүе буенча |

| | | |
|---|---|---|
| | | язу, ул тәкъдим иткән сүзләрдән сүзтезмә һәм җөмләләр төзеп язу.<br>Аерым темалар буенча өйрәнгән сүзләрне, сүзтезмә һәм җөмләләрне диктант итеп язу. Матур язу күнегүләрен үтәү. Сөйләм күнекмәләрен булдыру өстендә даими эшләү. Текст һәм аңа исеме туры килгәнен сайлап алу.<br>Җөмлә чикләрен билгеләү, җөмлә ахырына тыныш билгесен сайлау. Рәсем һәм бирелгән сүзләр буенча телдән хикәя төзү. Сүзнең мәгънәсен билгеләү (башта укытучы ярдәмендә). |
| **2 сыйныф** | | |
| Авазлар һәм хәрефләр. | 35 | Сузык авазлар һәм хәрефләр. Калын һәм нечкә сузыклар, аларны дөрес әйтү. Сингармонизм законы. Сузык авазларны белдерә торган хәрефләрнең дөрес язылышы.<br>Татар һәм рус телләрендә [а], [э], [о], [ө], [ы] авазларның әйтелеш үзенчәлекләре, бу сузыкларын белдерә торган хәрефләр һәм аларның дөрес язылышы.<br>*Я, ю, е* хәрефләре, алар кергән сүзләрне дөрес уку һәм язу.<br>Тартык авазлар. Яңгырау һәм саңгырау тартыклар. Алар кергән сүзләрне дөрес әйтү һәм язу; [w], [гъ], [къ], [х], [ч] тартыкларын дөрес әйтү, аларны белдерә торган хәрефләрнең язылышы. Татар теленең үзенчәлекле тартыклары [җ], [ң], [h]. Бу хәрефләр кергән сүзләрне дөрес язу күнекмәләре булдыру.<br>*Ц, щ* хәрефләре булган сүзләрне дөрес уку һәм язу.<br>*ъ* һәм *ь* хәрефләре кергән сүзләрне дөрес уку һәм язу.<br>Сүзлек һәм аңлатмалы диктантлар язу. |
| Сүз. | 8 | Сүзләрне иҗекләргә бүлү.<br>Иҗекләрнең калынлыгы-нечкәлеге сузык авазларга бәйле булуы. Сүз басымы турында мәгълүмат бирү.<br>Сүз тамыры. Аны дөрес табарга өйрәнү. |
| Морфология. Исем. | 8 | Исемнең мәгънәсе, сораулары турында белгәннәрне ныгыту. Ялгызлык исемнәр, аларның дөрес язылышы. Исемнәрнең берлек һәм күплек сан формалары. Күплек |

| | | |
|---|---|---|
| | | сан кушымчаларының дөрес язылышы, аларны рус теле белән чагыштыру. |
| Фигыль. | 9 | Фигыльнең мәгънәсе, сораулары. Фигыльләрнең заман формалары турында төшенчә бирү. Аларны рус теле белән чагыштырып күрсәтү. |
| Сыйфат. | 5 | Сыйфатның мәгънәсе, сораулары белән таныштыру. Предметның төрле билгеләрен белдерә торган сүзләр буларак, аларны сөйләмдә дөрес куллану. Бирелгән җөмләләрдән, әзер тексттан өйрәнгән сүз төркемнәрен табу, андый сүзләрне русчадан татарчага тәрҗемә итү, сөйләмдә дөрес куллану. |
| Синтаксис. | 13 | Сүзләрдән сүзтезмә һәм җөмләләр төзү. Җөмләнең баш кисәкләре турында мәгълүмат бирү, аларның урнашу тәртибен күзәтү, аны рус теле белән чагыштыру. Бирелгән сүзләр белән сүзтезмәләр һәм җөмләләр төзү күнекмәләре тәрбияләү. Тәрҗемә күнекмәләре булдыру. |
| Бәйләнешле сөйләм. | 24 | Тексттагы җөмләләрнең билгеле бер тәртиптә урнашуы Рәсем һәм терәк сүзләр ярдәмендә хикәя төзү.<br>Текстны үзгәртү, эчтәлеген сөйләү. |
| **3 сыйныф** | | |
| Сүз. | 10 | Әйтелеш һәм мәгънә бердәмлеге буларак сүз, аның туры һәм күчерелмә мәгънәләре. Синонимнар, омонимнар һәм антонимнар. Аларны тексттан табу, сөйләмдә дөрес һәм урынлы куллана белү.<br>Сүзлекләр турында мәгълүмат бирү һәм алар белән эшләргә өйрәтү. Сүзлек диктантлары язу. |
| Сүз төзелеше һәм ясалышы. | 10 | Тамыр һәм кушымча. Ясалма сүзләр. Тамырдаш сүзләр. Татар һәм рус телләрендә сүзләргә кушымчаларның ялгану тәртибе һәм үзенчәлекләре. Кушма һәм парлы сүзләр. |
| Морфология. Исем. | 10 | Берлек һәм күплек сандагы исемнәр. Уртаклык һәм ялгызлык исемнәр. Исемнәрнең килеш белән төрләнүе турында мәгълүмат бирү. Борын авазларына беткән исемнәрнең килеш белән төрләнеше. |

| | | |
|---|---|---|
| Сыйфат. | 5 | Синоним һәм антоним сыйфатлар. Аларны сөйләмдә дөрес куллану. Сыйфатларның җөмләдәге роле. Татар телендә сыйфат белән сыйфатланмышның бәйләнеше. |
| Сан. | 4 | Санның мәгънәсе, сораулары. Аны сөйләмдә дөрес куллану. Сан белән саналмышның бәйләнеше. Сөйләмдә микъдар саннарын куллану. |
| Алмашлык. | 5 | Гомуми мәгълүмат. Алмашлыкларның мәгънәсе, килеш белән төрләнеше. Сорау алмашлыклары турында мәгълүмат бирү. |
| Фигыль. | 10 | Фигыль турында өйрәнгәннәрне искә төшерү, аның заманнары. Хәзерге заман хикәя фигыльләрнең зат-сан белән төрләнеше, аларның сөйләмдә дөрес кулланылышы. Рус телендәге фигыльләрнең заманнары һәм зат-сан белән төрләнешендәге үзенчәлекләр. |
| Синтаксис. | 22 | Өйрәнелгән сүз төркемнәрен кулланып, сүзтезмә һәм җөмләләр төзү, аларны сөйләмдә дөрес куллану.<br>Әйтү максаты буенча җөмлә төрләре: хикәя, сорау, боеру, тойгылы җөмләләр. Җөмләнең баш кисәкләрен билгели белү.<br>Аергыч турында мәгълүмат бирү, аларны сөйләмдә дөрес куллану. Русча җөмләләрне татарчага тәрҗемә итү.<br>Татар телендә җөмләдә сүз тәртибе (ия белән хәбәрнең, аергыч белән аерылмышның урыннары). |
| Бәйләнешле сөйләм үстерү. | 26 | Сөйләм эшчәнлеге төрләрен үзләштерү. Укучыларның актив һәм пассив сүзлек байлыгын арттыру. Программа күләмендә диалогик һәм монологик сөйләмгә ия булу. Укыту һәм тормыш ситуацияләрендә татар<br>сөйләм әдәбе нормаларыннан файдалану. Текст өстендә эшләү. |
| **4 сыйныф** | | |
| Морфология.<br>Исем. | 10 | Яңгырау, саңгырау һәм борын авазларына беткән исемнәрнең килеш белән төрләнеше. Аларның дөрес әйтелеше, язылышы һәм сөйләмдә дөрес кулланылышы.<br>Морфологик анализ. |

| | | |
|---|---|---|
| Сыйфат. | 6 | Дәрәҗә формалары, аларның дөрес язылышы. Рус телендәге сыйфат дәрәҗәләреннән аермасы. |
| Сан. | 6 | Микъдар һәм тәртип саннары. Аларның сөйләмдәге әһәмияте, дөрес куллану күнекмәләре. Татар телендә саналмышның кулланылу үзенчәлекләре. |
| Алмашлык. | 8 | Күрсәтү алмашлыклары, аларның сөйләмдәге әһәмияте. Рус телендә бу алмашлыкларның мәгънәләрен белдерү юллары. |
| Фигыль. | 10 | Үткән һәм киләчәк заман хикәя фигыльләр. Аларның зат-сан белән төрләнеше.<br>Хикәя фигыльләрнең барлык заман формаларын зат-сан белән төрләндерү, аларны сөйләмдә дөрес куллану. |
| Синтаксис. | 29 | Татар һәм рус телләрендә сүзтезмә һәм җөмлә, аларда сүзләрнең урнашу тәртибе.<br>Җөмләнең баш кисәкләре. Иянең исем һәм зат алмашлыклары белән белдерелүе.<br>Хәбәрнең хикәя фигыль һәм сыйфатлар белән белдерелүе.<br>Җөмләнең иярчен кисәкләреннән аергыч, аның сыйфат һәм тәртип саннары белән белдерелүе.<br>Тәмамлык турында мәгълүмат.<br>Җыйнак һәм җәенке җөмләләр. |
| Бәйләнешле сөйләм үстерү. | 33 | Укучыларның актив һәм пассив сүзлек байлыгын үстерү. Монологик һәм диалогик сөйләм формаларына ия булу.<br>Үз фикереңне белдерү, аны дәлилләү. Татар телен йомшак белүчеләр белән аралашканда, татар сөйләм әдәбе үзенчәлекләрен саклау. Тәкъдим ителгән текстның планын төзү. |

## ЯЗМА ЭШ, ТЕСТ ҺӘМ ПРОЕКТ ЭШЛӘРЕНЕҢ ЯКЫНЧА САНЫ

| **Татар теле** | **1 сыйныф** | **2 сыйныф** | **3 сыйныф** | **4 сыйныф** |
|---|---|---|---|---|
| Сүзлек диктанты | - | 4 | 4 | 4 |
| Тикшерү диктанты | - | 4 | 4 | 5 |
| Изложение | - | 1 | 1 | 1 |
| Сочинение | - | 1 | 1 | 1 |
| Тест уздыру | - | - | - | 1 |
| Проектлар | - | - | - | 1 |
| Барлыгы | | 10 | 10 | 13 |